ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

22.11.2018 с. Верхний Услон 1373

«2019-2021 елларга Югары Ослан
муниципаль районының мәдәният
үсеше» муниципаль программасын
раслау турында

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү «Дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы Карарын үтәү максатларында (2017 елның 27 декабрендәге үзгәрешләре һәм өстәмәләр белән) һәм «2016-2018 елларга Югары Ослан муниципаль районы мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү» муниципаль программасының гамәлдә булу чоры тәмамлануга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2019-2021 елларга Югары Ослан муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасын (алга таба – муниципаль программа) расларга (1 нче Кушымта);
2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә муниципаль программаның төп чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. «Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә ел саен муниципаль программаны финанслауга акча карарга.
4. Карар үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Г. Ф. Камалетдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Әзерләде һәм
бастырды
Р.З. Нефедова

3 нөсхәдә

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 ноябрендәге 1373 номерлы карарына

1 нче Кушымта

**«РАСЛЫЙМ»**
**Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе**
**_____________ Л.С. Хакимзянов**
**«_____» __________ 2018 ел**

# «2019-2021 елларга Югары Ослан муниципаль районының мәдәният үсеше» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**2018**
**Югары Ослан авылы**

**«2019-2021 елларга Югары Ослан муниципаль районы мәдәниятен үстерү» муниципаль программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты. |
| Программаны эшләүче | МКУ«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге». |
| Программа эшләү өчен нигез | «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү «Дәүләт программасын раслау турында»2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары. |
| Программаның максатлары | Кешенең мәдәни тормышта катнашу һәм мәдәният учреждениеләреннән файдалануга конституцион хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы территориясендә мәдәни, музей кыйммәтләреннән файдалану, халыкка китапханә, мәдәни һәм музей хезмәте күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү. Югары Ослан муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шартлар тудыру һәм мәдәни потенциалны саклау. |
| Программаның бурычлары | Рухи-әхлакый кыйммәтләр, мәдәни мирас һәм иҗат потенциалы системасы буларак Югары Ослан муниципаль районының мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү һәм саклау.<br>Мәдәният өлкәсендә муниципаль учреждениеләр челтәрен саклау һәм үстерү.<br>Районның уңай имиджын формалаштыручы зур масштаблы иҗади проектларга ярдәм итү.<br>Эш формаларын камилләштерү, матди-техник базаны ныгыту, заманча технологияләр кертү исәбенә муниципаль мәдәният учреждениеләренең нәтиҗәле эшен тәэмин итү.<br>Район халкының мәдәни ял итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү күләмен һәм сыйфатын арттыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2019-2021 еллар |
| Программага исемлек | Программа үз эченә түбәндәге бүлекләрне ала:<br>1. «Проблеманы анализлау һәм бәяләү. Программаның максатлары»;<br>2. «Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары»;<br>3. «Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру»;<br>4. «Музей эшен үстерү»; |

| | |
|---|---|
| | 5. «Клуб учреждениеләрен үстерү»;<br>6. «Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту»;<br>7. Программаны Финанслау;<br>8. Программа белән идарә итү һәм аны гамәлгә ашыру механизмы;<br>9. Программаның максатлары һәм бурычлары Индикаторлары |
| Программаны һәм Программаның төп чараларын башкаручылар | МКУ «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге», районның мәдәният учреждениеләре. |
| Программаны көтелгән финанслау күләме һәм чыганаклары | Программаның барлык чараларын гамәлгә ашыру республика һәм җирле бюджетлардан, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклардан (түләүле хезмәтләрдән акчалар, иганәчеләр акчасы, хәйриячелектән акча) финанслауны күздә тота. Программаны финанслау күләме ел саен тиешле бюджетларны формалаштырганда ачыклана. |

**I Бүлек**
**Проблеманы анализлау һәм бәяләү. Программаның максатлары.**

Югары Ослан муниципаль районының 32 филиалы булган «Югары Ослан муниципаль районының үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе, 27 филиалы булган «Югары Ослан муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе, «Югары Ослан муниципаль районының Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе, «Югары Ослан муниципаль районының балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе бар.

Финанс күзлегеннән караганда, бүген мәдәният өлкәсе милли байлыкны тәшкил иткән матди кыйммәтләрне саклау, туплау барган социаль блокның бердәнбер өлкәсе булып тора.Үзенең реаль бәясе буенча милли байлыкның бер өлеше күп кенә хуҗалык тармакларының төп фондлары бәясен узып китә һәм ул шуның белән уникаль, инфляцияга каршы тора ала һәм байлык туплауның реаль чарасы булып тора.

Мәдәниятне саклау һәм үстерүнең актуаль мәсьәләләрен хәл итү комплекслы якын килүне, бөтен эшне заманча оештыруны, төгәл перспективалы планлаштыруны таләп итә. Әлеге программаны тормышка ашыру мәдәният өлкәсе учреждениеләре эшчәнлегендә булган кыенлыкларны җиңәргә, мәдәни мирасны саклау һәм районның мәдәни потенциалын үстерү буенча максатчан эш алып барырга мөмкинлек бирәчәк. Программа интеллектуаль, иҗади, оештыру һәм финанс мөмкинлекләрен берләштерүне күздә тота.

Программа иң беренче чиратта кирәкле чараларны билгели, алар якын киләчәктә булган потенциалны саклап калырга һәм Югары Ослан муниципаль районының мәдәният үсешенә яңа этәргеч бирәчәк. Аларның якын арада башкарылырга тиеш булганнары:

- иҗади потенциалны үстерү һәм яңадан торгызу өчен шартлар тудыру;
- мәдәни традицияләрне һәм бердәм мәдәни киңлекне саклау;
- заманча мәдәният һәм сәнгатьнең барлык төрләре һәм жанрлары үсешенә ярдәм итү, халыкның барлык катламнарын мәдәният кыйммәтләренә киң файдалану өчен шартлар тудыру;
- Югары Ослан муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең абруен яклау;
- профессиональ сәнгать үсешенә ярдәм итү.

Әлеге программаны тормышка ашыру гражданнарның районның мәдәни тормышында катнашу иреген тәэмин итүне, районның мәдәни тормышында иҗади үсеш һәм гражданнарның катнашу мөмкинлекләрен тәэмин итүне гарантияли.

Программа район чаралары, бәйрәмнәр оештыру аша район халкының ялын оештыру буенча муниципаль районга йөкләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Моннан тыш, әлеге Программа мәдәният өлкәсе хезмәткәрләрен район смотрлары, акцияләр, конкурслар, фестивальләр оештыру аша һөнәри укыту эшен күздә тота, бу исә, үз чиратында, кулланучыларның мәдәният

хезмәтләренең сыйфаты һәм үтемлелеге белән канәгать булуын арттыруга, мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын арттыруга китерәчәк.

## II Бүлек
## Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары

| № | Этап исеме | Тормышка ашыру сроклары | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Программаны тормышка ашыру | 2019-2021 еллар<br>Ел саен | Китап укучылар ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен китапханә фондларын тулыландыру. |
| | | 2019-2021 еллар | Авыл халкының мәгълүмат ресурсларыннан киң файдалана алуын тәэмин итү: авыл мәдәният йортларында Интернетка тоташу оештыру. |
| | | Ел саен | Китапханә хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын арттыру. |
| | | 2019 ел | «Уку+» проектын тормышка ашыру: ачык мәйданчыкларда, паркларда һәм скверларда укуны популярлаштыручы чаралар үткәрү өчен китапханә җиһазлары сатып алу. |
| | | Ел саен | Музей фондын тулыландыру, вакытлыча һәм күчмә күргәзмәләр үткәрү өчен җиһазлар сатып алу |
| | | 2019-2021 еллар | «Югары Ослан – Печищи» туган якны өйрәнү музееның туристик маршруты буенча түләүле экскурсияләр оештыру. |
| | | Ел саен | Музей эшенә мультимедиа технологияләрен кертү, эшнең яңа формаларын эзләү |
| | | Сентябрь – ноябрь | «Каинка көзе» район тарих-туган якны өйрәнү фестивален |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Ел саен | оештыру һәм үткәрү |
| | | 2019-2021 еллар<br>Ай саен | Югары Ослан районы территориясендә яшәүче халыкларның этномәдәни иҗатын саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән массакүләм чаралар үткәрү |
| | | 2019-2021 еллар | Район имиджын формалаштыру, район һәм республика күләмендәге чараларны оештыру һәм үткәрү. |
| | | 2019-2021 еллар | Татарстан тарихына, Югары Ослан муниципаль районының гореф-гадәтләренә һәм мәдәни мирасына ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | 2019-2021 еллар | Тамашачы аудиториясен киңәйтү; халыкның төрле катламнарының мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү: күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр спектрын киңәйтү, түләүле хезмәтләрдән керемне арттыру. |
| | | 2019-2021 еллар | Яшьләр һәм яшүсмерләрнең ял итү проблемаларын хәл итү. |
| | | Ел саен | Клуб учреждениеләре хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү. |
| | | Ел саен | Эшчәнлекнең инновацион формалары өчен шартлар тудыру: иҗади проектларга ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алуга конкурста |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | катнашу, мәдәният-ял учреждениеләре базасында яшүсмерләр һәм яшьләрнең иҗади-проект эшчәнлегенә юнәлдерелгән клуб формированиеләрен ачу. |
| | | Ел саен | Талантлы яшьләрне эзләүгә юнәлдерелгән «Созвездие - Йолдызлык» республика конкурсының район этабын оештыру һәм үткәрү. |
| | | Ел саен | Яшь талантларның иҗатын стимуллаштыру һәм аларга ярдәм итү: республика, бөтенроссия һәм халыкара конкурсларда балалар һәм яшүсмерләрнең катнашуын оештыру. |
| | | 2019-2021 еллар | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү. |
| | | 2019-2021 еллар | Мәдәният учреждениеләренең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру (финанслау булганда). |
| | | 2019-2021 еллар | Мәдәният учреждениеләренең террорчылыкка каршы куркынычсызлыгын тәэмин итү (финанслау булганда). |
| | | 2019-2021 еллар | Мәдәният учреждениеләренең эчке биналарын ремонтлау (финанслау булганда). |
| | | 2019-2021 еллар | «Капиталь ремонт», «Авыл клублары» республика программаларында катнашу |
| 2 | Йомгак ясау | 4 квартал<br>Ел саен | «2019-2021 елларга Югары Ослан муниципаль районы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мәдәниятен үстерү» программасын тормышка ашыру кысаларында мәдәният учреждениеләре эшчәнлеген анализлау. |
| 3 | «2022-2024 елларга Югары Ослан муниципаль районының мәдәният үсеше» Программасын эшләү | 4 квартал 2021 ел | «2022-2024 елларга Югары Ослан муниципаль районы мәдәниятен үстерү» программасын раслау. |

## III Бүлек
## Китапханә эшен үстерү

«Югары Ослан муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе китапханәләре эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре: мәгълүмати, интеллектуаль, патриотик, әхлакый, хокукый.

2018 елның 1 гыйнварына укучылар саны 14254 тәшкил итә. Китап фонды 248408 данә тәшкил итә. Халыкны китапханә хезмәте белән тәэмин итү – 86,6%.

2017 елда җирле бюджеттан китапханәләрне комплектлау өчен 707,2 мең сум акча бүлеп бирелгән, шул исәптән язылу өчен - 501,2 мең сум. 2017 елда түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган сумма 10,1 мең сум тәшкил иткән.

Мәгълүмат технологияләрен эшкә кертү халыкка хезмәт күрсәтү мөмкинлекләрен киңәйтте: текст туплау һәм бастыру, материалларны күчерү, документларны сканерлау, төрле мәгълүмат чыганакларына язылу, Интернет челтәреннән мәгълүмат бирү, «Консультант Плюс» мәгълүмат-хокукый системасы хезмәте.

Методик эшнең иң мөһим рәвешләреннән берсе-авыл китапханәләре хезмәткәрләренә методик һәм практик ярдәм күрсәтү максатыннан үзәк китапханә тарафыннан оештырыла торган семинарлар. Китапханәчеләр район халкы белән зур эш алып баралар: район мәгариф учреждениеләре укытучыларына һәм мәктәп укучыларына системалы рәвештә методик һәм практик ярдәм күрсәтәләр, китапханәләр һәм мәдәният учреждениеләре базасында ачык дәресләр, төрле күргәзмәләр оештыралар, мәгълүмати-танып-белү уеннары, викториналар, турнирлар, мәгълүмат сәгатьләре үткәрәләр. Шулай ук, үзәкләштерелгән китапханәләр системасында кызыксыну буенча 39 түгәрәк эшли.

**Китапханә эшен үстерү өлкәсендә төп бурычлар:**

- Югары Ослан муниципаль районы халкына китапханә хезмәте күрсәтүне оештыруны яхшырту;

- 27 китапханә фондын фәнни-популяр һәм сәнгать әдәбияты белән формалаштыру сыйфатын күтәрү;

- китапханә фондларының югары дәрәҗәдә сакланышын тәэмин итү;
- район мәдәни-мәгълүмат киңлеген үстерү;
- китапханә хезмәткәрләрен һөнәри яңадан әзерләү системасы аша укыту;
- оештыру чараларын тормышка ашыру**.**

Программа чаралары районда урнашкан китапханә эшчәнлеге системасын үстерүгә юнәлдерелгән.

Китапханә эшен үстерү шартларын тәэмин итү түбәндәге программа чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота:

| | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме барлыгы мең сум. | Көтелгән финанслау күләме, мең сум. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1 | «Югары Ослан үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУнең китапханә фондларын төрле чыганакларда китаплар белән тәэмин итүне оештыру һәм кирәкле тулылыгын тәэмин итү | РБ<br>МБ | 1500,00<br>450,00 | 500,00<br>200,00 | 500,00<br>200,00 | 500,00<br>200,00 |
| 2 | Авыл китапханәләрендә – филиалларда мәгълүмати үзәкләр булдыру | РБ<br>МБ<br>ВБ | Агымдагы финанслау | | | |
| 3 | Китапханә хезмәткәрләрен яңадан әзерләү | РБ<br>МБ<br>ВБ | 150,00 | 50,00 | 50,00 | 50,00 |
| 4 | Республика конкурсларында һәм грантларында катнашу | РБ<br>МБ<br>ВБ | Агымдагы финанслау | - | - | - |
| 5 | Ел саен китапханәләр | РБ | 150,00 | 50,00 | 50,00 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | көннәре үткәрү | МБ<br><br>ВБ | | | | 50,00 |
| 6 | Вакытлы матбугатка язылу оештыру | МБ | 1050,00 | 350,00 | 350,00 | 350,00 |
| 7 | Кулланучыларның интернет ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү | МБ | Агымдагы финанслау | | | |
| | | **Барлыгы** | 3300,00 | 1150,00 | 1150,00 | 1150,00 |

## IV Бүлек

## Музей эшен үстерү

Тарих-туган якны өйрәнү музее эшчәнлеге, барыннан да элек, туган якны үстерү буенча яңа стационар күргәзмәләр төзүгә, музейга килүчеләрне җәлеп итәргә сәләтле яңа мәдәни – белем бирү чараларын эшләүгә һәм районда рухи мәдәният үзәге буларак аның социаль әһәмиятен үстерүгә юнәлдерелгән.

### Эшчәнлек күрсәткечләре

| | 2017 |
|---|---|
| Килүчеләр саны | 3500 |
| Экскурсияләр | 183 |
| Лекцияләр | 24 |
| Күргәзмәләр | 21 |
| Массакүләм чаралар | 28 |
| Төп фонд | 8349 берәмлек |
| Фәнни-ярдәмче фонд | 381 |

«Югары Ослан муниципаль районы Туган якны өйрәнү музее» МБУ 2018 елның 1январена 183 экскурсия, 28 массакүләм чара, 21 күргәзмә һәм 24 лекция үткәрелде. Төп һәм фәнни-ярдәмче фонд 2016 ел белән чагыштырганда артмады. Фондның тулылыгын тәэмин итү өчен экспонатлар турындагы мәгълүматны бердәм электрон каталогта актуальләштерү эшен дәвам итәргә кирәк. Бу юнәлештә эш КАМИС мәгълүмати электрон системасында алып барыла, аңа ел саен хезмәт күрсәтү өчен акча бүлеп бирү таләп ителә.

2017 елда туган якны өйрәнү музеенда төп фондның 4348 экспонаты күрсәтелде.

Музей мәктәп музейларына системалы рәвештә методик, практик ярдәм күрсәтә. 2017 елда түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган сумма 29980 сум тәшкил иткән.

**Музей эшен үстерү өлкәсендәге программаның төп бурычлары булып тора:**

- музей белгечләренең квалификациясен күтәрү;
- музейның электрон мәгълүмат базасын булдыру;
- музейның төп һәм ярдәмче фондларын тулыландыру;
- музей педагогикасын үстерү, балалар аудиториясен туган якның мәдәни мирасына җәлеп итү;
- тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен өйрәнү, торгызу, консервацияләү һәм музейлаштыру проектларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;
- яңа музей экспозицияләрен камилләштерү һәм булдыру;
- район халкын музей хезмәтләре белән тәэмин итү буенча хезмәт күрсәтүне киңәйтү;
- мәдәни-тарихи мирасны саклау һәм пропагандалау;
- яшүсмерләргә һәм яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү;
- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- традицион халык мәдәнияте нигезендә рухи, гражданлык һәм патриотизм тәрбияләү.

Туган якны өйрәнү музее үсеше шартларын тәэмин итү түбәндәге программа чараларын тормышка ашыруны күздә тота:

| | Программа чараларының исеме | Финанслау чыганаклары | Финанслау күләме барлыгы мең сум. | Көтелгән финанслау күләме, мең сум. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1 | Музей хезмәткәрләрен яңадан әзерләү | РБ<br>МБ<br>ВБ | 30,00 | 10,00 | 10,00 | 10,00 |
| 2 | Республика конкурсларында һәм грантларында катнашу | РБ<br>МБ<br>ЭБ | Агымдагы финанслау | - | - | - |
| 3 | Ел саен уздырыла торган «Музей язы» | РБ<br>МБ<br>ЭБ | 90,00 | 30,00 | 30,00 | 30,00 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Мастер-класслар үткәрү, акцияләр, патриотик тәрбия, конкурслар, вакытлы күргәзмәләр оештыру | РБ<br>МБ<br>ЭБ | 360,00 | 120,00 | 120,00 | 120,00 |
| 5 | Клуб формированиеләрен, үзешчән берләшмәләрне төзү | РБ<br>МБ<br>ЭБ | Агымдагы финанслау | | | |
| 6 | Вакытлы матбугатка язылу оештыру | МБ | 10,500 | 3,00 | 3,500 | 4,00 |
| 7 | Куллануяыларның интернет ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү | МБ | Агымдагы финанслау | | | |
| | | Барлыгы | 490,500 | 168,00 | 168,500 | 169,00 |

## V Бүлек
## Район клуб (мәдәни-ял итү) учреждениеләрен үстерү

2018 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматларга караганда, мәдәни-ял итү учреждениеләре саны 32 (2017 елның 1 гыйнварына - 36) тәшкил итә, шул исәптән күчмә учреждениеләр – 2. 2017 елда муниципаль район мәдәният учреждениеләре тарафыннан 6386 (2016 елда – 6 719) мәдәни-ял чаралары уздырылган, бу 2016 ел күрсәткечләреннән 5% ка кимрәк, шул ук вакытта 1 клубка 200 чара туры килә (4 клуб кыскарту сәбәпле ябылды). КДУ дүрт учреждениесе ябылган һәм челтәрдән авария хәлендә буларак чыгарылган. Мәдәни-ял чараларының гомуми санынннан 1227 (2016 елда – 1 295) 14 яшькә кадәрге балалар өчен үткәрелә.

Районда 199 клуб оешмасы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра, аларда 2005 кеше йөри (2016 ел белән чагыштырганда 0,8% ка кыскарган). 4 клуб ябылу һәм клуб оешмалары саны кимү сәбәпле, бирегә килүчеләр саны кимеде. Гомуми санынннан 167-үзешчән халык иҗатын формалаштыру, шул исәптән 14 яшькә кадәрге балалар өчен 101-се 1026 кеше.

### Югары Ослан районының халык коллективлары

| № | Коллективның исеме | Карый | Оешу елы |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы | Район мәдәният йорты | 2001 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «ЭТО» (Эстетика. Театр. Аралашу) | | |
| 2 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы, «Волжанка» ветераннар хоры | Район мәдәният йорты | 2001 |
| 3 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы, «Иделкәй» татар вокаль ансамбле | Район мәдәният йорты | 2002 |
| 4 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы, «Кара-Ак» вокаль-инструменталь ансамбле | Район мәдәният йорты | 1975 |
| 5 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы, «Калинушка» рус җыры ансамбле | Печищи СДК | 1999 |
| 6 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы, «Каенкай» вокаль ансамбле» | Куралово СДК | 1994 |
| 7 | Татарстан Республикасының Халык үзешчән коллективы, «Карахуҗа кызлары» вокаль ансамбле | Карагуҗа  СДК | 1997 |

**Югары Ослан районының фольклор коллективлары**

| **№** | **Коллективның исеме** | **Карый** | **Оешу елы** |
|---|---|---|---|
| 1 | «Ак каен» татар фольклор коллективы | Яңа-Юл СК | 2003 |
| 2 | «Мирас» татар фольклор коллективы | Яңа-Болгар СК | 2010 |
| 3 | «Мәйдан» Балалар татар фольклор коллективы | Яңа-Болгар СК | 2011 |

Халыкның ялын оештыру сыйфатын яхшырту һәм район мәдәният йорты каршындагы клуб учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри әзерлеген күтәрү өчен методик хезмәт эшли, семинарлар, мастер-класслар оештырыла һәм үткәрелә.

**2017 ел өчен МБУ ЦКС (шул исәптән АКБ) эш күрсәткечләре**

| № | Күрсәткечләр | Барлыгы |
|---|---|---|
| 1 | Хезмәт күрсәтү зонасында чыгу саны | 87 |
| 2 | Чаралар саны, шул исәптән балалар өчен | 6 386 /1 227 |
| 3 | Ерак пунктларга чыгу саны | 23 |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Клуб оешмалары саны, шул исәптән балалар өчен | 201 /101 |
| 6 | Клуб формированиеләрендә катнашучылар саны, шул исәптән балалар саны | 2 009 /1 026 |

**Районның клуб учреждениеләрен үстерүдә Программаның төп бурычлары:**

- район территориясендә халыкның традицион мәдәниятен үстерү һәм аңа ярдәм итү;
- район клуб учреждениеләре, халык иҗаты коллективлары эшчәнлегенә ярдәм итү;
- мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтүне оештыру;
- мәдәни-мәгълүмати киңлекне үстерү.
- мәдәни-ял итү эшчәнлеге белгечләренең квалификациясен күтәрү.

Куелган бурычларны гамәлгә ашыру өчен шартлар белән тәэмин итү түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота:

| № | Программа чараларының исеме. | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме барлыгы мең сум. | Көтелгән финанслау күләме мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 |
| 1 | Район халкына социаль-мәдәни, мәгърифәт, күңел ачу характерындагы төрле хезмәтләр күрсәтү, сәнгать иҗаты белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру | РБ<br>МБ<br>ЭБ | 420,0 | 130,0 | 140,0 | 150,0 |
| 2 | Республика төбәк, Россия фестивальләре һәм конкурслары үткәрү. | РБ<br>МБ<br>ЭБ | 56,0 | 15,0 | 20,0 | 21,0 |
| 3 | Клуб формированиеләрен, үзешчән берләшмәләрне үстерү | РБ<br>МБ<br>ЭБ | 100,0 | 30,0 | 30,0 | 40,0 |
| 4 | Проектлар һәм программаларны эшләү һәм тормышка ашыру, халыкның төрле категорияләре белән эшкә юнәлдерелгән хезмәт күрсәтүнең яңа формаларын | РБ<br>МБ<br>ЭБ | 200,00 | 60,0 | 70,0 | 70,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм методларын гамәлгә кертү. | | | | | |
| 5 | Халык мәдәнияте традицияләрен саклау һәм торгызу: бәйрәмнәр, йолалар, фольклор. | РБ<br><br>МБ<br><br>ЭБ | <br><br>70,0 | <br><br>30,0 | <br><br>40,0 | <br><br>50,0 |
| 6 | Клуб учреждениеләре белгечләренең квалификациясен күтәрү | РБ<br><br>МБ<br><br>ЭБ | 0<br><br>60,0<br><br>0 | 0<br><br>20,0<br><br>0 | 0<br><br>20,0<br><br>0 | 0<br><br>20,0<br><br>0 |
| 7 | Мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре өчен яңа җиһазлар һәм инвентарь (костюмнар тегү) сатып алу һәм гамәлгә кертү | РБ<br><br>МБ<br><br>ЭБ | 0<br><br>500,0<br><br>130,0 | 0<br><br>130,0<br><br>40,0 | 0<br><br>170,0<br><br>40,0 | 0<br><br>180,0<br><br>50,0 |
| | | Барлыгы | 1536,0 | 455,0 | 530,0 | 581,0 |

## VI Бүлек
## Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту

Район мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасы буенча килеп туган хәлне анализлау күрсәтә:

«Югары Ослан муниципаль районы мәдәният үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе учреждениеләренең 50% ы капиталь ремонт яисә яңа мәдәни объект төзелешен таләп итә:

| | **Капиталь ремонт** |
|---|---|
| 1 | Печищи СДК |
| 2 | Яр Буе Моркваши СДК |
| 3 | Карагуҗа СДК |
| 4 | Киров СДК |
| 5 | Вахитов СДК |
| 6 | Яңа-Болгар СК |
| 7 | Патрикеево СК |
| 8 | Олы Мәми СДК |

| | |
|---|---|
| 9 | Уланово СК |
| 10 | Яңа-Юл СК |
| 11 | Канаш СК |
| 12 | Егедерево СК |
| | **Төзелеш** |
| 13 | СДК Соболевский ав. |
| 14 | Тат.Бурнаш СДК |
| 15 | Кызыл-Байрак СК |

2018 елда Туган якны өйрәнү музееның аерым биналарына җирле бюджет хисабына агымдагы косметик ремонт башланды, әмма музей бинасына капиталь ремонт кирәк. Шулай ук Мәйдан, Карагуҗа, Рус Макылы һәм Соболевский китапханәләренә капиталь ремонт кирәк.

- кайбер мәдәният учреждениеләре янгын куркынычсызлыгы таләпләренә тулысынча җавап бирми;

- мәдәни билгеләнештәге объектларның 50% тан артыграгында терроргa каршы куркынычсызлык чаралары үткәрергә кирәк, аларның үтәлү вакыты комиссия тикшерүе актлары һәм мәдәният учреждениеләренең терроргa каршы якланганлыгы дәрәҗәсе категорияләре буенча – 2019 елның апрель ае.

- мәдәният учреждениеләренең 20% агымдагы ремонт таләп итә.

- мәдәният учреждениеләрен музыкаль җиһазлар, сәхнә костюмнары, оргтехника белән тиешенчә тәэмин итмәү.

**Мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуда Программаның төп бурычлары:**

- «Капиталь ремонт», «Авыл клублары» республика программаларына мәдәни билгеләнештәге объектларны ел саен кертү;

Бюджетта каралмаган өстәмә акча булгәндә:

- мәдәният учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

- 2019 елда федераль закон нормалары нигезендә террорчылыкка каршы куркынычсызлык чараларын тәэмин итү буенча чаралар үткәрү;

- ел саен техник җиһазларны модернизацияләү, яктылык һәм тавыш - техника җиһазлары, музыка кораллары, китапханә һәм музей җиһазлары, компьютер техникасы, программа белән тәэмин итү;

- 2020 елга кадәр район авыл клубларын һәм авыл мәдәният йортларын Интернет челтәренә тоташтыру.

**Өстәмә акча бүлеп биргәндә 2019 елда янгын һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлык чараларын үткәрүгә ихтыяж**

| № | Чара | Бюджет акчалары | Үткәрү урыны | Бәясе / сум. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозуларны бетерү | МБ | РДК бинасы | 746 760.64 |
| 2 | Янгын сигнализациясен урнаштыру | МБ | РДК бинасы | 309 952.96 |
| 3 | Сөйләм хәбәренә янгын сигнализациясен урнаштыру. | МБ | РДК бинасы | 136 325.40 |
| 4 | Янгын сигнализациясен урнаштыру | МБ | 17 филиал | 1 424 000 |
| 5 | Тревога сигнализациясе кнопкасын урнаштыру һәм хезмәт күрсәтү | МБ | 25 филиал | 1 125 000 |
| 6 | Номер билгеләү җайланмасы | МБ | 2 филиал | 6 000 |
| 7 | Видеокүзәтү камералары урнаштыру | МБ | 12 филиал | 665 000 |
| 8 | Хәбәр итү һәм эвакуацияләү белән идарә итү системасын урнаштыру | МБ | 8 филиал | 1 044 000 |
| **Югары Ослан муниципаль районы «ҮКС» МБУ буенча барлыгы** | | | | **5 457039,00** |
| 10 | Янгын сигнализациясен урнаштыру | МБ | 2 филиал | 200 000,00 |
| 11 | Тревога сигнализациясе кнопкасын урнаштыру һәм хезмәт күрсәтү | МБ | Район үзәк китапханәсе | 35 000,00 |
| 12 | Тревога сигнализациясе кнопкасын урнаштыру һәм хезмәт күрсәтү | МБ | 24 филиал | 850 000,00 |
| 13 | Номер билгеләү җайланмасы | МБ | Үзәк китапханә (3 телефон номеры) | 10 000,00 |
| **Югары Ослан муниципаль районы «ҮКС» МБУ буенча барлыгы** | | | | **1 095 000,00** |
| 1 | Янгын сигнализациясен урнаштыру | МБ | Туган якны өйрәнү музее | 156 887,89 |
| 2 | Тревога сигнализациясе кнопкасын урнаштыру һәм хезмәт күрсәтү | МБ | Туган якны өйрәнү музее | 10 000,00 |
| 3 | 1 катта рәшәткә урнаштыру | МБ | Туган якны өйрәнү музее | 100 000,00 |

| | |
|---|---|
| | **266 887,89** |
| **БАРЛЫГЫ** | **6 818 926,89** |

Мәдәният учреждениеләренең янгын һәм террорчылыкка каршы куркынычсызлыгына өстәмә бюджет ассигнованиеләренә ихтыяҗ барлыгы 6 818 926,89 сум тәшкил итә.

**2019-2021 елларда район мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту (өстәмә акча бүлеп биргәндә) буенча кирәкле чаралар**

| № | Чаралар | Бюджет акчасы | Тасвирлама | Үтәү вакыты | Бәясе елга/ сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Капиталь, агымдагы ремонт, мәдәният учреждениеләре төзелеше | РБ/МБ | Мәдәният учреждениеләрен «Капиталь ремонт», «Авыл клублары» республика программаларына кертү; агымдагы ремонт үткәрү | 2019-2021 | Агымдагы финанслау |
| 2. | Тавыш көчәйткеч аппаратурасы сатып алу | МБ | 7 комплект җиһаз сатып алу (Тат.Борнаш авыл мәдәният йорты, Олы Мәми, Вахит, Соболевское, Киров, Канаш, Яңа-Болгар) | 2019 | 800 000,00 |
| 3. | Китап җиһазларын яңарту (стеллажлар сатып алу) | МБ | Даими яңартылган китап фондын урнаштыру өчен стеллажлар сатып алу (150 данә) | 2019-2021 | 745000,00 |
| 4. | Китапханә җиһазлары һәм җиһазлар сатып алу | РБ | «Уку+» проектын тормышка ашыру өчен җиһазлар сатып алу | 2019 ел | 100 000 сум. |
| 5. | Район китапханәләренә вакытлы матбугатка язылу | МБ | Ведомство язсыруны оештыру | Ел саен | 5000,00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Китаплар сатып алу | МБ/ РБ | Китап фондын тулыландыру | Ел саен | 250 000,00<br>50 000,0 0 |
| 7. | Укучыларга электрон хезмәт күрсәтүне тәэмин итү | МБ | Сканер-санагычлар; китап укучыларның бердәм билетлары; китап өчен штрих-кодлар сатып алу; | 2019-2021<br>Ел саен | 90 000,00<br>5000,00<br>10 000,0 0. |
| 8. | Авыл китапханәләре өчен оргтехника (принтерлар, МФУ) сатып алу | МБ | Районның 6 китапханәсен оргтехника белән тәэмин итү | 2019 | 50 00,00 |
| 9. | Музей җиһазларын һәм җиһазларны яңарту | МБ | Витриналар, стеллажлар һәм башка җиһазлар сатып алу | 2019-2020 | 534 900,0 0 |
| 10. | Туган якны өйрәнү музее эшенә мультимедиа чараларын кертү | МБ | КАМИС системасына техник хезмәт күрсәтү | Ел саен | 28 000,0 0 |
| 11. | Туган якны өйрәнү музее эшенә мультимедиа чараларын кертү | МБ | Музей эше өчен проекторлар сатып алу | 2019 | 31 700,0 0 |
| 12. | Туган якны өйрәнү музее эшенә мультимедиа чараларын кертү | МБ | Музейны штативлы экран белән җиһазлау | 2019 | 5 090,00 |
| | | | | **Барлыгы** | **3 199 690,00** |

## VII Бүлек
## Программаны Финанслау

Мәдәни-ял эшчәнлеген тәэмин итүгә (шул исәптән массакүләм чаралар, фестивальләр һәм конкурслар үткәрү, клуб формированиеләрен үстерү, костюмнар тегү һәм яңа сәхнә җиһазларын гамәлгә кертү) 2019-2021 елларда 1847,00 мең сум (499,00 мең сум – 2019 ел; 614,00 мең сум – 2020 ел, 734,00 мең сум – 2021 ел) бүлеп бирү күздә тотыла. Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә-3 500,00 мең сум (2019 елда 120,00 мең сум, 2020 елда 1220,00 мең сум, 2021 елда 1230,00 мең сум).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният өлкәсендә объектларның (территорияләрнең) терроргa каршы якланyуына карата таләпләрне раслау һәм әлеге объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортының формасын раслау турында» 2017 елның 11 февралендәге 176 номерлы Карарын (өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән) үтәү йөзеннән, һәм террорчылыкка каршы, шулай ук янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүгә, 6 818 926,89 сум күләмендә өстәмә акча бүлеп бирү зарур. 2019-2021 елларда учреждениеләрнең матди-техник базасын ныгытуның башка чараларына 3 199 690, 00 сум кирәк (өстәмә акча бүлеп бирелгән очракта).

Шулай ук, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 413 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы дәрәҗәсен күтәрүгә бюджет ассигнованиеләре үсешен тәэмин итәргә кирәк.

| Финанслау чыганаклары | Көтелгән бюджет финанслау, мең сум. | | |
|---|---|---|---|
| | **2019** | **2020** | **2021** |
| Барлыгы, шул исәптән | 51712,18 | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |
| Республика бюджеты: | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |
| Җирле бюджет: | 51597,18 | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Бюджеттан тыш чаралар: | 160,0 | Агымдагы финанслау | Агымдагы финанслау |

**VIII Бүлек**
**Программа белән идарә итү һәм аны гамәлгә ашыру механизмы**

«2019-2021 елларга Югары Ослан муниципаль районының мәдәният үсеше» программасын тормышка ашыру өчен җавап бирәләр:

- «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы-Назарова Марина Юрий кызы.
- «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге Исәп һәм хисап бүлеге» МКУ башлыгы Молгачева Анна Алексей кызы

Һәр бүлекчә өчен:

- «Халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру» - «Югары Ослан муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» директоры-Карасева Наталья Алексеевна.
- «Музей эшен үстерү» - «Югары Ослан муниципаль районының Туган якны өйрәнү музее» директоры-Шаһиәхмәтова Мария Сергеевна
- «Клуб учреждениеләрен үстерү» - «Югары Ослан муниципаль районы үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры-Мөхәммәтҗанова Елена Валерьевна.
- «Мәдәният учреждениеләренең матди - техник базасын ныгыту» - Югары Ослан муниципаль районының муниципаль бюджет мәдәният учреждениеләре директорлары.

**IX Бүлек**
**Программаның максатлары һәм бурычлары индикаторлары**

| Максатларның һәм бурычларның индикаторлары | Үлчәү берәмлеге | 1 нче ел | 2 нче ел | 3 нче ел |
|---|---|---|---|---|
| Китапханә хезмәте күрсәтү белән халыкны колачлау (ел саен 2 арттыру) | % | 2 | 2 | 2 |
| Китапханә/музейга килүчеләр саны (ел саен 2 % арттыру) | % | 2 | 2 | 2 |
| Китап фонды (ел саен 2 % арттыру) | % | 2 | 2 | 2 |
| Музей фондларын туплау (ел саен 2% арттыру) | % | 2 | 2 | 2 |
| Массакүләм мәдәни-ял чаралары саны | % | 5 | 5 | 5 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| (ел саен 5 % арттыру) | | | | |
| Мәдәни-ял чараларына килүчеләр һәм катнашучылар саны (ел саен 5 % арттыру) | % | 5 | 5 | 5 |
| Район, зона, өлкә, Бөтенроссия, халыкара әһәмияттәге күргәзмәләр, конкурслар, фестивальләр, акцияләр, саны (ел саен уңай динамика 2%) | % | 2 | 2 | 2 |
| Бастырыла торган мәгълүмати-методик материаллар саны (ел саен уңай динамика 5%) | % | 5 | 5 | 5 |
| Мәдәният хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү | кеше | 3 | 3 | 4 |
| Халыкның барлык социаль катламнарының мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә, шулай ук мәдәният өлкәсендә мәгълүмат алу мөмкинлеге | % | 60 | 70 | 80 |
| Кулланучыларның мәдәният хезмәтләренең сыйфаты һәм үтемлелеге белән канәгать булуы | % | 60 | 70 | 80 |
| Мәдәният хезмәтләренең сыйфаты белән канәгать булуны мониторинг системасын гамәлгә кертү | % | 60 | 65 | 70 |
| Татарстан Республикасында Югары Ослан муниципаль районының мәдәни үсеш рейтингын арттыру | % | 60 | 65 | 70 |

**Программаны гамәлгә ашыруның турыдан-туры нәтиҗәләре күрсәткечләре**

Программаны гамәлгә ашыру барышында тулысынча финанслау шарты белән түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү планлаштырыла:

| | **2018** | **2019** | **2020** |
|---|---|---|---|
| 1. Китап фондын арттыру (экземплярлар) | 800 | 850 | 880 |
| 2. Туристик объектны туристлык маршрутына кертү өстәмә керем китерәчәк (мең сум). | - | - | 50.0 |
| 3. Конкурслар, фестивальләр оештыру һәм үткәрү яшьләрне (мең кеше) җәлеп итәчәк. | 20.0 | 23.0 | 25.0 |

Программаны тормышка ашыруга тискәре йогынты ясаучы мөмкин тышкы факторларга түбәндәгеләр керә:

* финанслау булмау (тулы булмаган финанслау);

* законнарны үзгәртү.

Программа чараларының булмавы яки тулы булмаган финанслануы программаны тормышка ашыруның алдагы чорына үтәү срокларын һәм финанслау суммасын корректировкалау буенча чаралар үткәрү аша компенсацияләнә.